ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 ноябрь 2024ел № 7335

Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясының 3, 4 өлешләре, 158 статьясының 4 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы Карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 31, 36 пунктлары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы Приказы белән расланган дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү күләмен билгеләү буенча методик күрсәтмәләр, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы Приказы белән расланган күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар, торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча, шулай ук шундый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик рекомендацияләр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә, халык хокукларын һәм ихтыяҗларын яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы Карары, Башкарма комитетның 2017 елның 26 декабрендәге 8125 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар

өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту өчен түләү күләме торак урынны карап тоту буенча күрсәтелә торган хезмәтләр составына һәм күпфатирлы йортның конструктив үзенчәлекләренә бәйле рәвештә исәпләнә һәм үзгәртелә дип билгеләргә.

3. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны наемга алучылар өчен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) гомуми җыелышта түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак милекчеләре өчен күпфатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен торак урынны карап тотуга түләү составына керә торган түләү күләме Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан каралган тәртиптә билгеләнә дип билгеләргә.

4. Торак урыннан файдалану өчен түләү (наем өчен түләү) күләме, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 26 декабрендәге 8125 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү турында нигезләмәдә каралган коэффициентларны кулланып, торак урынның сыйфатына һәм төзекләндерелүенә, йортның урнашу урынына бәйле рәвештә билгеләнә.

5. Әлеге карар 2024 елның 1 ноябреннән үз көченә керә.

6. Башкарма комитет Карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2023 елның 3 ноябрендә «Челнинские известия» газетасының 80 санында бастырып чыгарылган «Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2023 елның 31 октябрендәге 10493 номерлы;

2) 2024 елның 6 сентябрендә «Челнинские известия» газетасының 63 санында, 2024 елның 4 сентябрендә «Шәһри Чаллы» газетасының 62 санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак

урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2023 елның 31 октябрендәге 10493 номерлы Карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 августындагы 5580 номерлы.

7. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитеи Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 1 ноябрендәге
7335 номерлы карарына
кушымта

Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләме

| № т/б | Түләү исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | 01.11.2024 елдан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Торак урынны наемга алу өчен түләүнең база күләме | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 8,30* |
| 2 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 3,75 |
| 3 | Гомуми файдалану урыннарын санитар карап тоту, шул исәптән: | | |
| 3.1 | йорт эчендәге гомуми файдалану урыннарын җыештыру | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 2,53 |
| 3.2 | йорт яны территориясен җыештыру | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 3,93 |
| 3.3 | чүп үткәргечләргә хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 1,45 |
| 3.4 | дератизация (дезинсекция) | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 0,22 |
| 4 | Төзелеш корылмаларына һәм биналарның инженерлык системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, шул исәптән: | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.1 | торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 4,07 |
| 4.2 | лифтларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 3,96 |
| 4.3 | йорт эчендәге электр челтәрләренә һәм электр җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 1,05 |
| 4.4 | йорт эчендәге газ белән тәэмин итү инженерлык челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 0,31 |
| 4.5 | җылылык алмашу җайланмасы белән җиһазландырылган йорт эчендәге сууткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 3,40 |
| 4.6 | йорт эчендәге үзәктән җылыту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 3,25 |
| 4.7 | янгынга каршы автоматика системасы (хезмәт күрсәтелгән очракта) | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 1,23 |
| 4.8 | домофоннар | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 0,61 |
| 5 | Чүп үткәргече булмаган күпфатирлы йортлар территориясендә контейнер мәйданчыгын карап тоту | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 0,41 |

Искәрмә:
* - Түләүнең туры килү коэффициентын исәпкә алып.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы — Г.А. Шәфыйкова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ